# Тамчы

**МБББУ «Икенче санлы Җәлил урта гомуми белем бирү мәктәбе» газетасы**

*ФЕВРАЛЬ №12 (56) 2016 нчы ел*


Батыр үлә, үлмәс ат алып,
Батырлыклар белән макталып.
Исемең калсын, үзең үлсәң дә,
Тарихларда укып ятларлык.

Муса Җәлил

## Бистәбез, мәктәбез кунаклар көтә



2016 нчы елның 15 нче февралендә герой-шагыйрь Муса Җәлилнең туган көне. Без быел аның тууына 110 ел тулуны билгеләп үтәбез. Легендар шагыйрь үзенең үлмәс шигырьләре, шәхси батырлыгы, ныклыгы, какшамас рухы белән бүген дә безгә үрнәк булып тора. Конференциябезнең "М.Җәлил — батырлык һәм иҗат үрнәге" дип аталуы шуңа ишарә.

Аңа багышланган фәнни бәйгенең укытучылар, укучылар күңелендә шундый яңгыраш алуы сөендерә. Без республикабызның 33 районыннан 246 фәнни-эзләнү эше кабул иттек. Үзләренең иҗат җимешләрен тәкъдим итүчеләр саны — 217. Ә бу аның иҗатын яратучылар, өйрәнергә теләүчеләр турында сөйли. Киләчәктә зур-зур фәнни ачышлар ясаучылар, шагыйрь-язучылар, драматурглар менә шушы парта артларында утыралар бит инде. Бүгенге эзләнүләре аларга киләчәккә омтылыш бирсен иде.

Сәнгатьле уку конкурсында 700 дән артык язма тыңланды. 700 дән артык укучыбыз Җәлил рухы белән яшәде, аның осталыгына сокланды.

Конференциягә килгән эшләр сайлап алынды. Аның финал өлеше 18 нче февраль көнне булачак. Фәнни эзләнүләрнең нәтиҗәләрен ясар вакыт җитте. Укучыларга уңышлар, җиңүләр телим.

**Г.Ф. Латифуллина,**
**икенче санлы Җәлил урта гомуми белем бирү мәктәбенең директоры**

## КОНФЕРЕНЦИЯЛӘР КӨНДӘЛЕГЕННӘН



Каһарман татар шагыйре Муса Җәлилнең олуг юбилее уңаеннан мәктәбебездә республикакүләм фәнни-гамәли конференция оештырылачак. Бу инде матур традициягә әверелде. Аны оештыруда ярдәмгә килгән "Җәлилнефть" нефть һәм газ чыгару идарәсенә, "Хезмәт Даны" музее җитәкчесе А.Ә. Галиәхмәтовага рәхмәтебез чиксез.

Республикакүләм оештырыла торган бу бәйге - өченчесе. Беренче тапкыр без аны герой-шагыйрьнең 105 еллыгы уңаеннан үткәрдек. Ул вакытта күбрәк үзебезнең районыбыз укучылары көч сынашты. 2011 нче елның февралендә конференция Сарман районы әдипләренең иҗатына багышланып оештырылды. Без аны Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә үткәрдек. Ул елны аның чикләре тагын да киңәйде. Конференциянең 5 секциясендә 127 укучының чыгышы тыңланды.

Бу уку елында конференция ТР Мәгарифне үстерү институты, "Җәлилнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсе, Сарман муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге белән берлектә оештырыла. Конференциягә әзерлек 3 юнәлештә барды. Укучылар каһарман шагыйрьнең тормышын, иҗатын өйрәнделәр, аның белән бәйле сәнгать әсәрләрен, тарихи урыннарны барладылар һәм фәнни эшләр белән чыгыш ясарга әзерләнделәр. 1-4 нче сыйныф укучылары аның шигырьләрен ятладылар, чыгышларын дискларга яздырып, аны жюри комиссиясенә җибәрделәр. Күңелләрендә иҗат ялкыны булган укучылар исә үзләре иҗат иткән шигырьләр, хикәя-экиятләр, эсселар белән катнашу мөмкинлеге алдылар. Шулай итеп, шагыйрь иҗатын тирәнрәк өйрәнергә, аңа булган хөрмәтебезне күрсәтергә, үзеңнең көчеңне сынап карарга тулы мөмкинлек булдырылды.



Мөгаллимнәребез, балалар бакчалары тәрбиячеләре дә үз тәҗрибәләре белән уртаклаштылар. Муса Җәлилнең иҗади мирасын дәресләрдә, дәрестән тыш чараларда куллану буенча да, тормыш юлын өйрәнүгә багышланган дәрес эшкәртмәләре дә, балалар иртәләре, шөгыльләр буенча методик материаллар да байтак тупланды. Муса Җәлил турында булган истәлек материалларыннан укучыларның белемнәрен бәяләү өчен контроль эш, тест биремнәре әзерләүчеләр дә бар. Гомумән, укытучылар да Муса Җәлил мирасы белән кызыксынуларын, аны укучыларга, балалар бакчаларында тәрбияләнүчеләргә өйрәтергә омтылуларын күрсәттеләр. Монда бары: "Афәрин!" диясе генә кала.

**Ландыш Шәйдуллина, конференция эше өчен җаваплы татар теле һәм әдәбияты укытучысы**




## 1 НЧЕ СЕКЦИЯ - «МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ ИҖАДИ МИРАСЫ»

**МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ ИҖАТЫН ӨЙРӘНҮГӘ БАГЫШЛАНА**

**301 НЧЕ КАБИНЕТ**

Җитәкчесе - Казан (Идел буе) федераль университетының Л.Толстой исемендәге филология һәм мәдәниятара багланышлар институты профессоры, филология фәннәре докторы, академик Хатыйп Йосыф улы Миннегулов. Комиссия әгъзасы: филология фәннәре кандидаты, ГАОУ ДПО "ТР Мәгарифне үстерү институты" доценты Р.Р. Шәмсетдинова



## 2 НЧЕ СЕКЦИЯ — «МУСА ҖӘЛИЛ СӘНГАТЬТӘ»

**МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ ТАТАР ТЕАТРЫ, СЫНЛЫ СӘНГАТЬ, МУЗЫКА ЕЛӘН БӘЙЛӘНЕШЕН КҮРСӘТҮ**

**303 НЧЕ КАБИНЕТ**

Җитәкчесе — Казан (Идел буе) федераль университетының Л.Толстой исемендәге филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының кафедра мөдире, филология фәннәре докторы Әлфәт Мәгъсүмҗан улы Зәкирҗанов. Комиссия әгъзасы: "Татнефть" ПАҖнең икъдисади-техник мәгълүмат һәм алдынгы тәҗрибәне тарату бүлеге җитәкчесе Н.З. Вәлиева, район мәгариф бүлеге методисты Назилә Тәлгать кызы Мәүләвиева



## 3 НЧЕ СЕКЦИЯ — «МУСА ҖӘЛИЛ ЭЗЛӘРЕ БУЙЛАП»

**М. ҖӘЛИЛНЕҢ ТОРМЫШ ЮЛЫН ӨЙРӘНҮЧЕ МУЗЕЙЛАР, ЭКСПОНАТЛАР ТАРИХЫ, ЯҢА ЭКСКУРСИОН МАРШРУТЛАР, МУЗЕЙ ЭКСПОЗИЦИЯЛӘРЕ ПРОЕКТЛАРЫ**

**303 НЧЕ КАБИНЕТ**

Җитәкчесе — филология фәннәре кандидаты, ТР Мәгарифне үстерү институты доценты Г. Н. Мөхәрләмова. Комиссия әгъзасы: филология фәннәре кандидаты, РТ Мәгарифне үстерү институты өлкән укытучысы Р.Ф. Саттарова, районыбызның Бөек Ватан сугышы һәм туган якны өйрәнү музее җитәкчесе Дания Кашипова

## 4 НЧЕ СЕКЦИЯ— "МУСА ҖӘЛИЛ БЕЗНЕҢ ЙӨРӘКЛӘРДӘ"



**УКУЧЫЛАРНЫҢ ИҖАДИ ЭШЛӘРЕ (ШИГЫРЬЛӘР, ӘКИЯТЛӘР, ХИКӘЯЛӘР, СӘХНӘ ӘСӘРЛӘРЕ)**

**308 НЧЕ КАБИНЕТ**

Секция эшендә катнашалар: Татарстанның халык шагыйре, Россия Федерациясенең дәүләт премиясе лауреаты, Тукай бүләге иясе Ренат Харис, Казан шәһәренең 20 нче гимназия директоры К.Насыйри исемендәге бүләк иясе Рәхимә Арсланова, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, Ш.Маннур премиясе лауреаты Р.Ахунҗанова.



## УКЫТУЧЫЛАР ҺӘМ ТӘРБИЯЧЕЛӘР ӨЧЕН ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛЛӘР

**306, 307 НЧЕ КАБИНЕТЛАР, АКТЛАР ЗАЛЫ**

Түгәрәк өстәл эшендә катнашалар: Татарстан Республикасының Милли музее җитәкчесе, тарих фәннәре докторы Г.Р.Нәҗипова, **Муса Җәлил музей-фатиры җитәкчесе Н.Г.Фаттахова**, Яр Чаллы дәүләт педагогия университеты доценты, педагогия фәннәре кандидаты Абдулла Алишның туганы Илдар Абдулла улы Алишев, **Абдулла Баттал туганы Фәрит Баттал,** Сарман районы Иске Кәшер авылында яшәүче Зиннәт Хәсәновның туганнары

## МУСА ҖӘЛИЛ ШИГЫРЬЛӘРЕН СӘНГАТЬЛЕ УКУЧЫЛАР БӘЙГЕСЕНӘ ЙОМГАК ЯСАУ



**ҖӘЛИЛ МӘДӘНИЯТ САРАЕ**

Конкурска йомгак 16 нчы февраль көнне ясалды. Укучыларның язмаларын бәяләүдәге хезмәтләре өчен конференциянең мәгълүмати партнеры- "ТАТМЕДИА" АҖнең "Сарман" мөхәррият үзәге филиалы коллективына, шәхсән филиал директоры — баш редакторы А.Ә. Сабировага рәхмәтебезне җиткерәбез.

**КОНФЕРЕНЦИЯ ЭШЕНДӘ УҢЫШЛАР ТЕЛИБЕЗ!**